ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**09.06.2020**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1029**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия турында» 2750 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарында кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия составын, кушымта нигезендә, яңа редакциядә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге «Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия турында» 2750 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне, кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану буенча территориаль ведомствоара комиссия турында» 2019 елның 16 декабрендәге 2750 номерлы карарының комиссия составы өлешендә 1 пунктны һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарының 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары – М.З. Усмановка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 09 июнендәге 1029 номерлы
карарына
1 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе** | |
| Усманов Марат Зәкәри улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| **Комиссия рәисе урынбасары** | |
| Гататдинова Светлана Владимировна | «Зеленодольск шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры |
| **Комиссия секретаре** | |
| Калистратова Ольга Николаевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлеге баш белгече |
| **Комиссия әгъзалары** | |
| Стерякова Анастасия Сергеевна | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль-икътисадый фаразлау һәм анализлау бүлеге начальнигы |
| Шакиров Марат Госман улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Кулланучылар базары бүлеге начальнигы |
| Антонова Мария Михайловна | «Зеленый Дол» инвестиция үзәге» ЗМР АУ җитәкчесе |
| Әфләтунова Альбина Марат кызы | Федераль суд приставлары хезмәтенең ТР буенча идарәсенең Зеленодольск район бүлеге начальнигы-өлкән суд приставы (килешү буенча) |
| Билалиева Лариса Витальевна | ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм халыкны социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районында социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Путин Алексей Евгеньевич | Татарстан Республикасы буенча 8нче Федераль салым хезмәтенең Зеленодольск районара инспекциясе начальнигы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Сабурский Алексей Вячеславович | ТР Зеленодольск шәһәре, Зеленодольск һәм Югары Ослан районнары буенча РФ Пенсия фондының идарә начальнигы (килешү буенча) |
| Грошев Игорь Иванович | Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Светлов Роман Викторович | Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең начальник урынбасары – полиция начальнигы (килешү буенча) |
| Донченко Эдуард Николаевич | Дәүләт учреждениесенең 14 нче филиалы – Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе директоры (килешү буенча) |
| Антипов Константин Сергеевич | Зеленодольск муниципаль районы профсоюз оешмаларының Координация советы рәисе(килешү буенча) |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 09 июнендәге 1029
номерлы карарына
кушымта

**Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

1. Зеленодольск муниципаль районында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча территориаль ведомствоара комиссия (алга таба - Комиссия) Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, формаль булмаган хезмәт базарын кыскарту һәм икътисадта тискәре тенденцияләрне җиңү, шулай ук виза нигезендә Россия Федерациясенә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә булган ихтыяҗны билгеләү эшендә катнашу максатларында оештырылган.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, 2002 елның 25 июлендәге «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 115-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 12 сентябрендәге «Россия

Федерациясенә виза нигезендә килүче чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итүгә ихтыяҗны билгеләү, чит ил гражданнарына хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясенә керү өчен чакырулар бирү квотасын раслау турында, шулай ук Россия Федерациясенә эшкә рөхсәтләр нигезендә килүче чит ил гражданнарына бирү квоталарын раслау хакында»800 номерлы карарына, Россия Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе карарларын үтәү;

эш бирүчеләрнең минималь куллану бюджетының бәясеннән ким булмаган күләмдә хезмәт хакын вакытында түләвен тәэмин итүгә, аның буенча бурычларны түләүгә, бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен түләүгә, халыкның, шул исәптән пенсия яшендәге гражданнарның реаль керемнәрен арттыру буенча мониторинг үткәрү; шулай ук пенсия алды яшендәге затларга карата эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү буенча эшне координацияләү;

кызыксынган дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары инициативасы буенча Зеленодольск муниципаль районы территориясендә урнашкан аерым хуҗалык итүче субъектларының банкротлыкка чыгуын кисәтү буенча чаралар күрү турындагы тәкъдимнәрне анализлау, шулай ук күрсәтелгән хуҗалык итүче субъектларына карата тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны бөлгенлек (банкротлык) процедураларын башлап җибәрүгә вәкаләтле органнар каравына кертү;

Зеленодольск муниципаль районында социаль ярдәм һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәлелеген, сыйфатын, адреслылыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру турында тәкъдимнәр әзерләү;

күләгә икътисады һәм формаль булмаган хезмәт базары өлкәсендә тенденцияләр мониторингы;

территориаль комиссияләр эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү;

башкарма органнарның икътисад өлкәсендәге процессларга контрольне гамәлгә ашыручы башка органнар белән үзара хезмәттәшлеге һәм Зеленодольск муниципаль районында хезмәт законнарын үтәлешен контрольдә тоту;

4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ,оештыру-хокукый формаларына карамастан, предприятие, учреждение һәм оешма җитәкчеләрен тыңлауга;

Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләрен карау һәм хәл итү өчен кирәкле мәгълүматны (шул исәптән документларны) билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

үз утырышларына Зеленодольск муниципаль районы структур бүлекчәләренең, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затларын, шулай ук эшче

төркемнәр (Советлар, комиссияләр), хуҗалык итүче субъектларның җитәкчеләрен чакырырга;

Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, шулай ук хуҗалык итүче субъектларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрергә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә комиссия тарафыннан ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү максатларында, закон нигезендә карарлар кабул итү өчен, мәгълүмат җибәрергә;

Комиссия эшендә ярдәм күрсәтү өчен хокук саклау органнарын, шулай ук Комиссия һәм күрсәтелгән органнар арасында төзелә торган тиешле килешүләр нигезендә дәүләт күзәтчелеген һәм контролен гамәлгә ашыручы башка органнарны чакырырга, аларга Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр бирергә;

кирәк булганда, тиешле тәртиптә Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, хуҗалык итүче субъектларны Комиссия компетенциясенә керүче карарлар һәм башка материаллар әзерләүдә катнашу өчен җәлеп итәргә;

Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча эшче төркемнәр булдырырга.

5. Комиссия Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасарлары, Комиссия секретаре һәм Комиссия әгъзалары составында формалаша. Комиссия әгъзалары саны 10 кешедән дә ким булмаска тиеш.

6. Комиссия составына социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өч яклы территориаль комиссия, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнар, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләре керә. Комиссия әгъзасы булмаган очракта, аны шул ук оешма вәкиле тавыш бирү хокукы белән алмаштыра. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен җәмәгать башлангычларында гамәлгә ашыралар.

7. Комиссия составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

8. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Комиссия утырышы, әгәр утырышта әгъзаларның гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, гамәли хокуклы дип санала.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта, Комиссия утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Утырыш беркетмәсенә Комиссия рәисе тарафыннан 5 эш көне эчендә имза салына.

9. Комиссия рәисе:

Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларга рәислек итә;

Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган карарлар кабул итә.

10. Комиссия рәисе урынбасары:

Комиссия рәисе булмаганда , анын вазыйфаларын башкара; Комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти.

11. Комиссия секретаре:

Комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

Комиссия эшен оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

беркетмәләр һәм кирәкле документларны саклый.

12. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия һәм түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

Комиссия утырышларында катнашалар;

карау өчен чыгарылган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан танышалар;

Комиссиягә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән срокка утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрәләр;

Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар буенча фикер алышуда катнашалар һәм аларны кабул иткәндә тавыш бирәләр;

Комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үтиләр.

13. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.